Кукмара муниципаль районы
Березняк авыл җирлеге Башкарма комитеты

# КАРАР

«27» май, 2025 ел № 35

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең иң зур күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Гражданнарның аларга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын арендалау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең иң зур күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү методикасы, «2025 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 21 мартындагы 172/пр номерлы боерыгы (01.04.2025 №81705 теркәлгән), «Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе нормативын билгеләү методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2024 елның 28 мартындагы 215/пр номерлы боерыгы (17.05.2024 №78191 теркәлгән), Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә ТР Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең иң зур күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең түбәндәге иң зур бәясен билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керем күләме иң зур күрсәткече 27 405,25 сум тәшкил итә:

1.2. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек бәясенең иң зур күләме түбәндәгечә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 992 682 сум;

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен – 1 985 364 сум;

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен – 2 978 046 сум;

1.2.4. Дүрт кешелек гаилә өчен – 3 970 728 сум;

1.2.5. Биш кешелек гаилә өчен – 4 963 410 сум;

1.2.6. Алты кешелек гаилә өчен – 5 956 092 сум;

1.2.7. Җиде кешелек гаилә өчен – 6 948 774 сум;

1.2.8. Сигез кешелек гаилә өчен – 7 941 456 сум.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресына, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Ф.Шәрипов

Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 27 маендагы 35 номерлы карарына кушымта

# ГАИЛӘНЕҢ ҺӘР ӘГЪЗАСЫНА ЯКИ ЯЛГЫЗ ЯШӘҮЧЕ ГРАЖДАНГА ТУРЫ КИЛГӘН КЕРЕМНЕҢ ИҢ ЗУР КҮЛӘМЕН ҺӘМ ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫ ЯКИ ЯЛГЫЗ ЯШӘҮЧЕ ГРАЖДАННЫҢ МИЛКЕНДӘГЕ ҺӘМ 2025 ЕЛГА САЛЫМ САЛЫНЫРГА ТИЕШЛЕ МӨЛКӘТНЕҢ БӘЯСЕН БИЛГЕЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба – исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,

монда:

СЖ – исәп-хисап күрсәткече;

НП – муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ – муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган торак урын мәйданының бер квадрат метрының Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга кире кайтарылмый торган субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый торган уртача базар хисабы бәясе.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ= 55 149*18= 992 682 сум

б) ике кешелек гаиләгә:

СЖ=55 149*36= 1 985 364 сум

в) өч кешелек гаиләгә:

СЖ=55 149*18*3= 2 978 046 сум

г) дүрт кешелек гаиләгә:

СЖ=55 149*18*4= 3 970 728 сум

д) биш кешелек гаиләгә:

СЖ=55 149*18*5= 4 963 410 сум

е) алты кешелек гаиләгә:

СЖ=55 149*18*6= 5 956 092 сум

ж) җиде кешелек гаиләгә:

СЖ=55 149*18*7= 6 948 774 сум

з) сигез кешелек гаиләгә:

СЖ=55 149*18*8= 7 941 456 сум

2. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек бәясенең иң зур күләме СЖ ның исәпләнгән күрсәткечәнә тигез дип кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керемнең иң зур күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урыны сатып алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә, – гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән, агымдагы шартларда түбәндәге формула буенча исәпләнә торган СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак бина сатып алу өчен банктан ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык гомуми керем дәрәҗәсеннән чыгып:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (l - (1 + ПС)-КП ) / (0,25 х РС),

монда:

ПД – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм агымдагы шартларда түбәндәге формула буенча исәпләнә торган СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак бина сатып алу өчен банктан ипотека кредиты алу өчен кирәк булган уртача айлык гомуми керемнең иң зур күләме;

СЖ – исәп-хисап күрсәткече;

ПС – кредит буенча бер айлык процент ставкасы (унарлы вакланма), (Ставка елга 8,5 %, ягъни 8,5/100/12 айга =0,0071 айга);

КП – кредитның бөтен срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) – 180 ай;

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 – кредит буенча түләүнең гаиләнең гомуми айлык кереме белән нисбәте;

«Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр союзы» Коммерцияле булмаган партнерлыгының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2025 елның 11 февралендәге 64 номерлы хаты нигезендә 2025 елда Кукмара муниципаль районы буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 55 149 сум тәшкил итә.

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең иң зур кыйммәтен исәпләү:**

| НП – торак урын норма сы (кв. м) | СЖ – торак сатып алу өчен базар бәясе (СЖ = РС х РЦхНП) (сум) | РС – гаилә әгъза лары саны (кеше ) | РЦ – 1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум) | ПС – кредит буенча бер айлык процент ставкасы, % | КП – кредит буенча түләүләр нең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте | Кредит буенча түләүнең гомуми айлык керемгә нисбәте | ПД – Керемнең иң зур кыйммәте (сум) (гаиләгә) | керемнең иң зур кыйммәте (сум) (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| | | | 55 149 | 8,5/100/12= 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,25 | | |
| 18 | 992 682 | 1 | 55 149 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,25 | 27 405,25 | 27 405,25 |
| 36 | 1 985 364 | 2 | 55 149 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,50 | 54 810,50 | 27 405,25 |
| 54 | 2 978 046 | 3 | 55 149 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,75 | 82 215,75 | 27 405,25 |
| 72 | 3 970 728 | 4 | 55 149 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1 | 109 621,00 | 27 405,25 |
| 90 | 4 963 410 | 5 | 55 149 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1,25 | 137 026,25 | 27 405,25 |
| 108 | 5 956 092 | 6 | 55 149 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1,50 | 164 431,50 | 27 405,25 |
| 126 | 6 948 774 | 7 | 55 149 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1,75 | 191 836,75 | 27 405,25 |
| 144 | 7 941 456 | 8 | 55 149 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 2,00 | 219 242,00 | 27 405,25 |